# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КАРМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## Карар

**№ 34** **30 январь 2017 ел**

**Татарстан РеспубликасыАксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советы

Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Юстиция органына Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр дәүләт теркәвеннән соң махсус мәгълүмати стендларда игълан ителергә тиеш.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Кармәт авыл җирлеге башлыгы: Ф.З.Мусабиков

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Кармәт авыл җирлеге Советының
2017 нче елның 30 нче январендәге 34нчы санлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан РеспубликасыАксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

1.7 статьяны 15 пункт белән тулыландырырга) түбәндәге редакциядә

«15) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында"2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру.

2. 47 статьяның 2 өлеше түбәндәге редакциядә абзац белән тулыландырылсын:

"Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру.